ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» август 2019ел № 322

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
Районында «Әгерҗе-Красный Бор» Яңавыл – Яңа Бәзәкә
юлын реконструкцияләүдә линияле объект территориясен
ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру
проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Әгерҗе-Красный Бор» Яңавыл – Яңа Бәзәкә юлын реконструкцияләүдә линияле объект территориясен ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проектын расларга.
2. Селезнев Андрей Анатольевичны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә, ышанычнамәсез «дәүләт кадастр исәбен алып бару һәм хокукларны дәүләти теркәү гамәлгә ашырыла торган затлар» турында 15нче статья, «күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13.07.2015 № 218-ФЗ Федераль закон (2019 елның 1 гыйнварындагы редакциядә) нигезендә, муниципаль берәмлек милкенең кадастр исәбен алып бару һәм дәүләт теркәве үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать итүдә вәкаләтле вәкил итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И.Шамсутдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**